РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19 май 2026 ел Буа шәһәре № 6-12

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2017 елның 24 мартындагы 4-18 номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга муниципаль мөлкәтне озак сроклы нигездә биләүгә һәм (яисә) файдалануга бирү максатларында өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) Азат муниципаль мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законнар (09.04.2026 редакциясендә), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 21 августындагы 645 номерлы «Федераль милек биргәндә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү турында» карары (03.07.2025 редакциясендә) нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2017 елның 24 мартындагы 4-18 номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга муниципаль мөлкәтне озак сроклы нигездә биләүгә һәм (яисә) файдалануга бирү максатларында өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) Азат муниципаль мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның д пунктчасында һәм 7 пунктның а пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты карары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе карары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы
вазифасын башкаручы И.Ф. Еремеев